**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения

В целях совершенствования правового регулирования отношений в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов **постановляю**:

1. Внести в раздел III параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения, утвержденных Указом Президента Республики Татарстан от 12 апреля 2013 года № УП-303 «Об определении параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 14 декабря 2013 года № УП-1216, от 12 июня 2014 года № УП-572, от 23 апреля 2015 года № УП-412, от 16 июля 2015 года № УП-654, от 15 августа 2015 года № УП-724, от 10 февраля 2016 года № УП-131, от 9 июля 2016 года № УП-588, от 7 июля 2017 года № УП-608, от 19 мая 2018 года № УП-381, от 30 мая 2018 года № УП-397, от 26 июля 2018 года № УП-541, от 19 февраля 2019 года № УП-130, от 24 мая 2019 года № УП-294, от 24 июня 2019 года № УП-361 и от 23 мая 2020 года № УП-305), следующие изменения:

а) пункты 7 – 10 изложить в следующей редакции:

«7. Запрещается любительская и спортивная охота на глухаря в период летне-осенне-зимнего сезона охоты 2020 года и весеннего сезона охоты 2021 года во всех охотничьих угодьях, за исключением охотничьих хозяйств: «Азнакаевское», «Беркут», «Глухарь» и «Юкя».

8. Запрещается любительская и спортивная охота на тетерева в период летне-осенне-зимнего сезона охоты 2020 года и весеннего сезона охоты 2021 года во всех охотничьих угодьях, за исключением охотничьих хозяйств: «Баганинское», «Верхнеуслонское», «Камско-Устьинское» (используется местной общественной организацией «Камско-Устьинское охотничье хозяйство») и «Теньковское».

9. Запрещается любительская и спортивная охота на серую куропатку в период летне-осенне-зимнего сезона охоты 2020 года во всех охотничьих

угодьях, за исключением охотничьих хозяйств: «Азнакаевское», «Аксубаевское», «Апастовское», «Баганинское», «Баиковская роща», «Барс», «Беркут», «Большекургузинское», «Бугульминское», «Буинское», «Бутино-Шешминское», «Верхнеуслонское», «Елабужское», «Зеленодольское», «Кайбицкое», «Камско-Устьинское» (используется обществом с ограниченной ответственностью «Вепрь»), «Камско-Устьинское» (используется местной общественной организацией «Камско-Устьинское охотничье хозяйство»), «Караишевское», «Куйбышевское», «Ласка», «Мизиновское», «Никольское», «Пестречинское», «Свиногорье», «Тарханы», «Теньковское», «Тетюшское», «Фазан», «Юкя», «Ямашское», «Янтыковское», а также общедоступных охотничьих угодий Азнакаевского, Аксубаевского, Алексеевского, Алькеевского, Альметьевского, Бугульминского, Дрожжановского, Кайбицкого, Менделеевского, Спасского, Тетюшского и Ютазинского районов.

10. Запрещается любительская и спортивная охота на зайца-русака в сезон охоты 2020/2021 года в охотничьих хозяйствах: «Ак Барс», «Албаевское», «Баганинское», «Бакчасарайское», «Берсут», «Волжское», «Вятский берег», «Вятское», «Егерь», «Елабужское», «Забава», «Камский берег», «Красноборское», «Кукморское», «Лубянское», «Марал», «Муслюмовское», «Нурма», «Омара», «Охотничьи традиции», «Охотничьи традиции 2», «Сармановское», «Свиногорье», «Северное», «Урман», «Усинское», «Учебно-опытный Сабинский лесхоз», «Южное», а также в общедоступных охотничьих угодьях Агрызского, Алексеевского, Алькеевского, Елабужского, Мамадышского, Менделеевского, Муслюмовского, Новошешминского, Сармановского и Чистопольского районов.»;

б) дополнить пунктом 17 следующего содержания:

«17. Запрещается с 1 января по 28 (29) февраля любительская и спортивная охота на кабана всеми способами охоты, за исключением охоты со стационарных вышек, расположенных на высоте не менее двух метров над уровнем земли.».

2. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
11 августа 2020 года
№ УП-473

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында**

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы, 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы, 2018 елның 30 маендагы ПУ-397 номерлы, 2018 елның 26 июлендәге ПУ-541 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге ПУ-130 номерлы, 2019 елның 24 маендагы ПУ-294 номерлы, 2019 елның 24 июнендәге ПУ-361 номерлы һәм 2020 елның 23 маендагы ПУ-305 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, аулау параметрларының III кисәгенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 – 10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. 2020 елның җәйге-көзге-кышкы ау чорында һәм 2021 елның язгы ау чорында «Азнакай», «Беркут», «Глухарь» һәм «Юкә» аучылык хуҗалыкларыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә суерга һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

8. 2020 елның җәйге-көзге-кышкы ау чорында һәм 2021 елның язгы ау чорында «Баганино», «Югары Ослан», «Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы файдалана) һәм «Тәмте» аучылык хуҗалыкларыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә көртлеккә һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

9. 2020 елның җәйге-көзге-кышкы ау чорында «Азнакай», «Аксубай», «Апас», «Баганино», «Баек урманы», «Барс», «Беркут», «Олы Карагуҗа», «Бөгелмә», «Буа», «Бута-Чишмә», «Югары Ослан», «Алабуга», «Зеленодольск», «Кайбыч», «Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана), «Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы файдалана), «Караеш», «Куйбышев», «Ласка», «Мизин», «Никольский», «Питрәч», «Свиногорье», «Тархан», «Тәмте», «Тәтеш», «Фазан», «Юкә», «Ямаш», «Янтык» аучылык хуҗалыкларыннан, ә шулай ук Азнакай, Аксубай, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Бөгелмә, Чүпрәле, Кайбыч, Менделеевск, Спас, Тәтеш һәм Ютазы районнарының ачык аучылык биләмәләреннән тыш, барлык аучылык биләмәләрендә соры кыр тавыгына һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

10. 2020/2021 еллар ау сезонында «Ак Барс», «Албай», «Баганино», «Бакчасарай», «Берсут», «Идел», «Вятский берег», «Вятское», «Егерь», «Алабуга», «Забава», «Камский берег», «Красный бор», «Кукмара», «Лубян», «Марал», «Мөслим», «Норма», «Омара», «Аучылык традицияләре», «Аучылык традицияләре 2», «Сарман», «Свиногорье», «Төньяк», «Урман», «Усы», «Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы», «Көньяк» аучылык хуҗалыкларында, шулай ук Әгерҗе, Алексеевск, Әлки, Алабуга, Мамадыш, Менделеевск, Мөслим, Яңа Чишмә, Сарман һәм Чистай районнарының ачык аучылык биләмәләрендә соры куянга һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17. 1 гыйнвардан 28 (29) февральгә кадәр кабан дуңгызына җирдән кимендә ике метр биеклектә урнашкан стационар каланчалардан файдаланып аулаудан тыш, барлык төр ау ысуллары белән һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 11 август
№ ПУ-473